КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1288

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы, 2018 ел, 07 май, 327 нче, 2018 ел, 30 июль, 614 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктка «билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында конкурентлыкны үстерү максатларының һәм бурычларының өстенлеген тәэмин итү буенча» сүзләрен өстәргә;

3.2 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләүне тәэмин итү (01.05.01.01*);»;

егерме беренче абзацка «тәэмин итү» сүзләреннән соң «гамәлгә ашыру» сүзләрен өстәргә;

IV бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.2.16 бүлекчә өстәргә:

«4.2.16. Төбәк әһәмиятендәге аеруча саклана торган табигый территориягә карата әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документацияне килештерә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин